КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1741

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636; 2017 ел, 15 май, 282 нче; 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 205 нче; 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче; 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче; 2020 ел, 2 март, 155 нче; 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 70 нче; 2023 ел, 30 март, 380 нче; 2023 ел, 2 ноябрь, 1410 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста җиңүчеләр – Конкурста беренче 30 урынны алган Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәләре: I төркем буенча – 11 урын, II төркем буенча – 11 урын һәм III төркем буенча – 8 урын;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста приз алучылар – Конкурста 31 нче урыннан 120 урынга кадәр урын алган Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәләре: I төркем буенча – 30 урын, II төркем буенча – 30 урын һәм III төркем буенча – 30 урын;»;

3.10 пунктның беренче абзацында «кертә» сүзе алдына «электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасыннан файдаланып электрон рәвештә» сүзләрен өстәргә;

3.11 пунктта «тапшыра» сүзе алдына «электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасыннан файдаланып электрон рәвештә» сүзләрен өстәргә;

3.17 пунктта:

икенче абзацта «I урынга» сүзләрен «Конкурста җиңүчеләргә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «II урынга» сүзләрен «Конкурста приз алучыларга» сүзләренә, «800,0» саннарын «477,77» саннарына алмаштырырга;

дүртенче – алтынчы абзацларны төшереп калдырырга;

3.18 пунктта «дипломнары» сүзеннән соң «, истәлекле билгеләре яисә вымпеллары» сүзләрен өстәргә;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Конкурсның II этабында Конкурста беренче 30 урынны алган: I төркем буенча – 11 урын, II төркем буенча – 11 урын һәм III төркем буенча – 8 урын алган Конкурста җиңүчеләр Конкурс йомгаклары буенча җиңгән Конкурс үткәрелгәннән соң кимендә ике ел үткәч кенә Конкурста катнаша алалар.»;

4.4 пунктның 4.4.1 пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «$C_i = N_1 \times R_1 + N_2 \times R_2$,»;

бишенче абзацта «Конкурста I урынны алган» сүзләрен «Конкурста җиңүчеләр –» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Конкурста II урынны алган» сүзләрен «Конкурста приз алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче – тугызынчы абзацларны төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «Конкурста I урынны алган» сүзләрен «Конкурста җиңүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «Конкурста II урынны алган» сүзләрен «Конкурста приз алучылар» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче – ундүртенче абзацларны төшереп калдырырга;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында:

III бүлектә:

2 пунктның өченче графасында «Кергән мөрәҗәгатьләр» сүзеннән соң «, шул исәптән социаль челтәрләргә һәм мессенджерларга кергән мөрәҗәгатьләр» сүзләрен өстәргә;

5 пунктның өченче графасында «идарәче компанияләр» сүзләрен «идарәче оешмалар (идарәче оешма булганда һәм аның белән хезмәттәшлек булмаганда, әлеге хезмәттәшлекнең гамәлгә ашырылмавы сәбәпләрен күрсәтергә кирәк)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында:

2 пунктның икенче графасында «санап үтелгән чараларның нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «, халык акчасын территорияне үстерүгә җәлеп итү эше» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның өченче графасында «10» саннарын «8» санына алмаштырырга;

4 пунктның өченче графасында «10» саннарын «8» санына алмаштырырга;

5 пунктның икенче графасында «категорияләрдәге гражданнарга» сүзләреннән соң «, хәрби операциядә катнашучы затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына» сүзләрен өстәргә;

7 пунктның өченче графасында «10» саннарын «8» санына алмаштырырга;

8 пунктның өченче графасында «10» саннарын «8» санына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «9. | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең муниципаль хакимият органнары, идарәче оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге (киңәшмәләр, уртак чаралар, муниципаль органнар, идарәче оешмалар вәкилләре белән очрашулар һәм аларда карала торган мәсьәләләр саны) | Иң зур күрсәткеч – 10 балл, иң кечкенә күрсәткеч – 1 балл»; |

әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипнең 7 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 декабрь, 1741 нче карары редакциясендә)

Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшли торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс төркемнәре

| Төркемнәр | Муниципаль берәмлек исеме | 2023 елның 3 ноябренә территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | Заявка-ларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I төркем – шәһәр округлары | Казан шәһәре | 77 | 39 |
| | Яр Чаллы шәһәре | 78 | 39 |
| | Барлыгы | 155 | 78 |
| II төркем – халкы 60 мең кешедән күбрәк булган шәһәр җирлекләре | Әлмәт шәһәре | 36 | 18 |
| | Бөгелмә шәһәре | 3 | 2 |
| | Алабуга шәһәре | 15 | 8 |
| | Зеленодольск шәһәре | 4 | 2 |
| | Лениногорск шәһәре | 13 | 7 |
| | Түбән Кама шәһәре | 27 | 14 |
| | Чистай шәһәре | 8 | 4 |
| | Барлыгы | 106 | 55 |
| III төркем – халкы 60 мең кешегә кадәр булган шәһәр җир-лекләре һәм авыл җирлекләре | Әгерҗе шәһәре | 7 | 4 |
| | Азнакай шәһәре, Азна-кай муниципаль районы составына керә торган Актүбә шәһәр тибын-дагы поселогы | 17 | 9 |
| | Алексеевск муниципаль районы составына керә торган Алексеевск шә-һәр тибындагы посе- | 3 | 2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | логы | | |
| | Арча шәһәре | 5 | 3 |
| | Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 24 | 12 |
| | Буа шәһәре | 6 | 3 |
| | Чүпрәле муниципаль районы составына керә торган Иске Чүпрәле авыл җирлеге | 1 | 1 |
| | Алабуга муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 14 | 8 |
| | Зәй шәһәре | 11 | 6 |
| | Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы | 4 | 2 |
| | Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган барлык шәһәр һәм авыл җирлекләре | 21 | 11 |
| | Кукмара шәһәре | 4 | 2 |
| | Лаеш шәһәре һәм Лаеш муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 29 | 15 |
| | Мамадыш шәһәре, Мамадыш муниципаль районы составына керә торган Красная Горка авыл җирлеге | 9 | 5 |
| | Менделеевск шәһәре | 5 | 3 |
| | Минзәлә шәһәре | 5 | 3 |
| | Түбән Кама муниципаль районы составына керә торган Кама Аланы шәһәр тибындагы посе- | 2 | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | логы | | |
| | Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 13 | 7 |
| | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы | 7 | 4 |
| | Сарман муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 3 | 2 |
| | Болгар шәһәре | 1 | 1 |
| | Тәтеш шәһәре | 5 | 3 |
| | Тукай муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 5 | 3 |
| | Ютазы муниципаль районы составына керә торган Урыссу шәһәр тибындагы поселогы | 1 | 1 |
| | Барлыгы | 202 | 111 |
| Барысы | | 463 | 244 |

«Татарстан Республикасында
елның иң яхшы территориаль
иҗтимагый үзидарәсе» республика
конкурсы турындагы нигезләмәгә
5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 декабрь, 1741 нче
карары редакциясендә)

Форма

## «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашуга заявкаларны бәяләү кәгазе

| | |
|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | |

| Заявканың номеры | Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | Конкурс комиссиясе әгъзасының критериеләр буенча бәясе (балл) | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 (граждannar мөрәҗәгате) | 2 (халык белән эшләү) | 3 (физкультура һәм спорт) | 4 (массакүләм мәдәни эш) | 5 (халыкның социаль яклanmaган катламнарына, хәрби операциядә катнашучы затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү) | 6 (төзекләндерү һәм яшелләндерү) | 7 (массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү) | 8 (тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары, ирекле халык дружиналары белән хезмәттәшлек итү һ.б.) | 9 (муниципаль хакимият органнары, идарәче оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү) | заявка бәясенең (балларның) гомумиләштерелгән күрсәткече |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

____________________________________
(конкурс комиссиясе әгъзасының имзасы)

__________
(дата)

«Татарстан Республикасында
елның иң яхшы территориаль
иҗтимагый үзидарәсе»
республика конкурсы турындагы
нигезләмәгә 7 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 декабрь, 1741 нче
карары редакциясендә)

Грантларны төркемнәргә бүлү

| Бүләкләнү-челәр | Грантларның гомуми саны | I төркем | II төркем | III төркем |
|---|---|---|---|---|
| Конкурста җиңүчеләр | 30 | 11 | 11 | 8 |
| Конкурста приз алучылар | 90 | 30 | 30 | 30 |
| Барысы | 120 | 41 | 41 | 38 |